**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ АТАБАЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

422635 с. Атабаево,
ул. Молодежная д.1
тел:   4-87-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ  МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**Атабай АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
422635 Атабай авылы,
Яшьләр  урамы, 1 нчы йорт,
тел:    4-87-41

---

**2024елның «25» июне** **198 номер**

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры вазыйфаи оклады күләмен арттыру турында (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш)**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатларында (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш), Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 24 мартындагы 132 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакы турында нигезләмәгә  түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның хезмәт хакы түбәндәге зурлыкта билгеләнә:

| Вазифа | Халык саны белән муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| --- | --- |
| | 3,5 мең кешегә кадәр |
| Баш бухгалтер | 23 700 рублей |

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге башкарма комитетының штат расписаниесенә баш бухгалтер вазифасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 мең кешедән артык.».

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Лаеш муниципаль районының Рождественское авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районының Атабайо авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Атабай**
**авыл җирлеге Советы рәисе : Л.Р.Хәлилова**